

ISSN 0868-4545

Салават күпере

Укучым! Бел, сине
Аң-нурлы юл көтә.
Ул якты юл һәрчак
БЕЛЕМ гә
илтә!

Беренче! Беренчеләр...

Беренче сентябрь. Беренче сыйныф. Беренче укытучы. Беренче кыңгырау. Беренче дәрес. Беренче тәнәфес...

Ошбу сентябрьдә тәүге мәртәбә мәктәп бусагасы аша Белем иленә узучылар үзләре дә — БЕРЕНЧЕ. Ягъни мәсәлән, БЕРЕНЧЕЛӘР, Беренче Сыйныф Укучылары...

Бәлки күпләрегез әти-әниләрегез, абый-апаларыгыз, әби-бабайларыгыз, якын туганнарыгыз яисә тәрбиячеләрегез ярдәмендә укырга һәм язарга өйрәнгәндер дә инде. Әгәр шулай икән, андыйларга бездән мактау сүзләре ирешсен...

Беренчеләр...

Беренчеләргә бездән һәрчак бүләк әзер.

Бүләк — «Салават күпере» журналы.

Рәхим итегез Әдәбият һәм Сәнгать мәктәбенә: сөенеп керегез шигырь, әкият, җыр, рәсем дәресләренә, куанып чыгыгыз яңа тәнәфесләргә...



Рәссам Светлана ПРИВИНА

© "Салават күпере", 1999 ел

Шигърият дәресе

Рөстәм Мингалим

Көч җыйдым

Көч җыйдым мин,
көч эчтем
әнкәемнең сөтеннән.
... Көчем артты үпкәндә
әткәемнең битеннән.

Бик яраттым җәйләрне,
кышларны да яраттым.
Йөгергәндә — көч тоттым,
егылсам да — көч таптым.

Тордым билгә таянып,
көчем билгә җиткәндә.
Абыйдан да көч алдым,
ул борынга чиерткәндә.
Узып шунда борынны,
түбәмә
җитте көчем.
... Мин
җиде ел
көч җыйдым
мәктәпкә бару өчен!



Тәнәфес

Яфраклы уен

Бу уен төрле агачлар үскән җирдә уйнала. Һәр балага берәр яфрак таратыла: әйтик, каен яисә усак, өрәңге, юкә... яфраклары. Алып баручы «Үз өеңне тап!» дигән әмер бирүгә, һәр бала үзе тапкан яфракның агачы янына йөгерә. Үз агачларын дөрес һәм тиз тапкан балалар җиңүче дтп исәпләнәләр.

Заһид Мәхмүди

Аулак өйдә

Уйнап туйгач, Нәнис белән Нәнүс телевизор карарга утырдылар. Анда рогаткадан атып шаярырга яратучы бик шук малай турында нәфис фильм бара иде. Менә ул агач башында утырган бер песнәкне бәреп төшерде. Әшәке малай бик елгыр булып чыкты. Аны хәтта милиционер абый да тота алмады.

— Абый, — диде шул чак Нәнис, Нәнүснең кабыргасына төртеп, — бу әшәке малайны милиционер абыйга тотып бирәбезме?

— Ничек итеп?— диде Нәнүс, гаҗәпләнеп.

— Телевизорны сүтәбез дә, якасыннан өстерәп чыгарабыз.

— Ы–ы, ул бездән зуррак.

— Нигә куркасың, без бит икәү!

— Ярамый, — дип җавап бирде абый кеше, энесенең тәкъдимен кире кагып. — Аның кыены миңа эләгәчәк.

— Телевизорның арткы капкачын ачабыз да...

— Син күкеле сәгатьне сүткәндә дә шулай дигән идең. Аннан соң, бер тотынгач, соңгы шөребенә кадәр сүтеп бетердең.

Нәнис авызын турсайтты.

— Мин бит күке күкәй салмады микән дип кенә...

— Таптыңмы соң?

— Үзең күреп тордың ич, нинди күкәй булсын ди анда? Күкәйне алып, күптән очып чыгып киткән иде инде ул.

— Бу юлы да шулай булачак. Син бит әйбер ватарга яратасың.

— Син милиционер абыйга булышырга теләмисеңмени? Ә үзең, зур үскәч, милиционер абый булам, дисең тагын!

Тарткалаша торгач, абый кеше риза булды.

— Ярар, синеңчә булсын, акылга утыртырга кирәк аны, — диде ул, кулларын йодрыклап.

Телевизорның арткы капкачын ачып, эчкә күз салгач, малайлар югалып калдылар. Нәнүс, аптырап, колак артын кашып куйды.

— Качкан, — диде ул, — милиционер абый да күренми.

Нәнис исә абыйсын тынычландырырга кереште:

— Борчылма, абый, ул теге әшәке малайны куып киткәндер.

— Ерак китә алмаганнардыр әле, эзләргә кирәк, — диде Нәнүс, ныклы карарга килеп.

Малайлар өйнең астын-өскә китереп бетерделәр, әмма милиционер белән әшәке малайны таба алмадылар.

— Борчылма, абый! — Нәнис кулын абыйсының иңенә куйды. — Икенче юлы кача алмас, без аны барыбер тотачакбыз.

Телевизорның арткы капкачын ябып куйгач, кәефләре кырылган балалар яңадан машиналы уйнарга утырдылар.



Рәссам Иллар НӘФИЕВ

Зиннур Гыйбадулла
шигыре һәм көе

Туган көнем

Бүген минем туган көнем –
Әзерләндем бик күптән:
Җырлар, шигырьләр ятладым,
Сөйләргә торып иртән.


Кушымта:
Лә–ли–лә, лә–ли–лә,
Минем исмем Камилә.
Дус кызларым белән бергә
Уйныйсым гына килә.

Курчакларның битен юып,
Чәчләрен үреп салдым.
Яңа теккән күлмәкләрен
Кидереп уйнап алдым.

Лә–ли–лә, лә–ли–лә,
Минем исмем Камилә.
Курчакларым бигрәк матур –
Уйныйсым гына килә.

Битләренә кершән ягып,
Ислемай табып сөрттем.
Үзләренә исем эзләп,
Аптырап, йөдәп беттем.

Разия, Нажия,
Иң зур апам Галия.
Апам исемнәрен куштым
Иркәләп сөя–сөя.




Котлыйбыз!


Зиннур абыегыз Гыйбадулла (Гыйбадуллин) — халкыбызның танылган композиторы, өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә матур-матур көйләр иҗат итүче. Шушы көннәрдә мөхтәрәм Композиторга 70 яшь тулды. Без Аны олуг бәйрәме белән чын күңелдән котлыйбыз һәм Аңа саулык-сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез!



Рөстәм Кутуй шигырьләре

Көтүче

Мин — көтүче. Кәҗә көтәм,
Кулда — чыбыркы.
Чыбыркы тоткан беләкләр
Җәен чыныкты.

Сикерә дә менеп китә
Кәҗә гел өскә,
Коймаларны бәреп керә,
Күрсә кәбестә.

Мин — көтүче, солдат кебек
Һәрвакыт сакта.
Көне буе чаба торгач,
Кичкә аксата.

Тәмле була, татлы була
Чык төшкән үлән...
Ә кичләрен сыйланам мин
Җылы сөт белән.

Кәҗә көтәм. Үзем көтәм
Еллар үтүен.
Үсеп җиткәч, тапшырырлар
Сыер көтүен.

Әтәч

Кикрикләре уттай яна,
Очып килә каршыга,
Йөгерә дә менеп куна
Зәңгәр койма башына.

Койрыклары — төсле фонтан,
Атлап килә хан сыман...
Дөнья матур, кояш көлә,
Әтәч кенә ярсыган.

Көязләнә, ыспайлана,
Гүя карый көзгегә...

Ачыла бар тәрәзәләр,
Сүз артыннан сүз тезәләр:
— Канат кагып очып китәр!
— Түбәләрдән биек үтәр!
— Болытларга барып җитәр!
— Чү, ашыкма, түз генә!

Очмый әтәч болытларга,
Куна койма башына.
«Кикрикүк!» — дип ул
дусларын
Уятырга ашыга.

Урысчадан **Разил Вәлиев** тәрҗемә кылды.



Үгез бозау урам буйлап
Чабып йөрде, уйнады.
Чабып килде, сөзеп атты
Урамдагы койманы.

Әй сөенде, әй куанды:
Имеш, ул шундый көчле!
Коймада зур тишек калды,—
Бер күзле дию төсле.

Бакча буйлап бара үгез,
Үләннән коеп чыкны.
Ә маңгае шул арада
Йодрыктай шешеп чыкты.

Койма карый ачуланып
Бер сыңар күзе белән.
Ә бозау шат, бакчада бит
Тезеннән аның үлән.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Өзем төнәфес

Әйдәгез, уйныйбыз!



Әнгел белән шайтан

Балалар барысы да йөзләре белән стенага борылып баса. Берсе аларның башларын борып, йөзләрен карап йөри. Балалар барысы да авызларын йомган була. Йөзен күрсәтүче көлмәсә — әнгел, көлсә — шайтан була. Шулай итеп уйнаучылар әнгел белән шайтанга бүленеп беткәч, шайтаннар әнгелләрне тотарга тырышалар.

Әнгелләр:
Эт йөри урамда,
Хәбәре юк буранда.
Әнгеллеккә җиңеллек,
Шайтанга авырлык! —
дип җырлыйлар. Тотылса, әнгел шайтанга әйләнә.

Җиз бүкән

Бу уен күбрәк малайлар арасында җәй көне тышта уйнала.

Балалар түгәрәк ясап, «җиз бүкән» булып, чүгәләп утыралар. Һәрберсенең артында бер малай басып саклап тора. Арада бер малай бүкәнсез калдырылган була. Ул арттан килә дә «сакчы» белән сүз башлый:

— *Җиз бүкән, җиз бүкән сатлык микән?*

— *Җиз бүкән сатлык икән.*

— *Күпме хак алыр икән?*

— *Хак ярым хак, пот ярым борчак икән.*

— *Әйдә йөгерешеп карыйк, кем алыр икән,* — диләр дә түгәрәк тышыннан берберсенә каршы йөгереп әйләнәләр. Кем иң элек әйләнеп килеп җитсә, җиз бүкән шуныкы була.



Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Шагыйрә Йолдызның балалар өчен язган китаплары

Антенналы бәрәңге 1994
Зоопарк 1997
Шигырьле чәй 1999



Рәссам Диләрә Нәүрүзова

Кадерле дускай!

Журналның урта битен иплэп кенә алып, кара сызыклар буенча кисегез, сары сызыклар буенча бөкләгез дә, килеп чыккан кисәкләрне, бит саннарына карап, китап итеп җыегыз. Булгач-булгач, чын китап булсын — уртасын ике урыннан төппәп куегыз.

©«Салават күпере» китапханәсе.

Кем уяткан?

Кайдан әле бөреләр
Яз килгәнен белделәр?
Яшел башларын сузып,
Кояшка үрелделәр.

Сәгать дигән нәрсәнең дә
Ни икәнен белмиләр.
Ничек итеп һәр яз саен
Уяналар бөреләр.

Җиребезгә язлар килгәч,
Кошлар кайткач көньяктан,
Йоклап яткан бөреләрне
Тамчы тамып уяткан.

— Торыгыз, җитәр! — дигән,
— Артыкка китәр! — дигән.





Шагыйрә
Йолдыз апагыз
уллары Сәйдәш, Ядкарь һәм Айнур белән.

Шаян көй

Бер көй кереп качты гармун
Телләре арасына.
Ләкин белмим кайсындадыр:
Агында, карасында?
Бер көй кереп качты шунда —
Калмадыгызмы күреп?
Табалсам иде шул көйне
Кайда качканын белеп.
Бәлки ул көй минем белән
Качыш-качыш уйныйдыр.
Бәлки ул көй минем белән
Шаярырга уйлыйдыр.
Андый шаян көй дә булгач,
Ул бит миңа охшаган.
Миңа охшаган да булгач,
Табачакмын, ышанам.

Билгеле урын

Безнең өйдә һәрнәрсә
Үзенең урынын белә:
Пәлтә чөйгә эленә,
Китап киштәгә менә.
Бияләйләр, оеклар
Җылыны яраталар.
Яккан мич кырыенда
Рәхәтләнеп яталар.
Һәр нәрсәнең урыны бар:
Тәртипле машиналар,
Уенчыклар, уйнап туйгач,
Тартмага ашыгалар.
Мендәрләр ята диванда,
Ә күлмәкләр шкафта...
Кайвакытта миңа дигән
Урын да бар почмакта.





Колаклар нигә кирәк?

Беләсезме икән сез
Нигә кирәк колаклар?
Ишетергә генә түгел,—
Күрергә кирәк алар.
Ничек алай дисезме?
Хәзер, хәзер аңлатам:
Үзегез дә шаккатырсыз
Бу гаҗәп яңалыктан.
Колак тотып тормаса,
Күзгә төшә ул бүрек,
Бүрек төшеп каплагач,
Берни дә булмый күреп.
Күзең капланган килеш
Кыен шул ул йөрергә.
Димәк, колак ярдәм итә
Безгә әйбәт ... күрергә.

Ни файда?

Яңгыр ява коеп-коеп,
Иләкләп тә чиләкләп.
Атлыймын мин әкрен генә,
Ашыкмыйча бик иплəп.
Әни мине ашыктыра,
Әйдә, тизрәк, ди, өйгә.
Мин атлыйм шул бер көйгә,
Ерак бит әле өйгә.
Ашыгып ни файда ла,
Яңгыр ява анда да.
Әгәр яңгыр туктасамы —
Мин дә кызык итәрмен.
Мин дә кызык итәрмен.
Тизрәк чабып китәрмен дә
Өйгә кайтып җитәрмен.



Яңгыр ничек боз булган?

Иртән яңгыр ява иде,
Тамчы булып тама иде.
Әйләнгән бозга кичен.
Уйлыйсыңмы: «Ни өчен?»

Көн суытып җибәргән дә
Яңгыр тамчысы туңган.
Мамык тунын киеп алган —
Ак кар булуы шуннан.





Җавап

Ләлә бүген урамда
Туп уйнады көнозын.
Әнисе чакырып алды:
— Караңгы төшә, кызым...


Керми кызчык.
Вәт бәла,
Җавап та тапкан әнә:
— Әйдә төшсен, ватылсын—
Һәм тизрәк яктырсын.






Алсу һәм
Илшат
Җиһаншиннарның
рәсемнәре (Кукмара)











Инглиз телен өйрәнүче дускай!

Бүгенге дәресне Казан дәүләт педагогия университеты доценты Алсу Фоат кызы Вәлиева алып бара. Г.Тукайның «Шүрәле»сен инглиз теленә тәрҗемә итүче дә Алсу апагыз

Игътибар! Дәрес башланды...

Габдулла Тукай



Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл — Кырлай диләр;
Җырлаганда көй өчен «тавыклары җырлай» диләр.

Гәрчә анда тумасам да, мин бераз торган идем,
Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.

Ул авылны, — һич онытмыйм, — һәр ягы урман иде,
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.

Зурмы? дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә,
Халкының эчкән суы бик кечкенә — инеш кенә.

Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава,
Җил вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява.

Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың, бер чиләк.

Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.

G.Tukai "Shurale"

Translated from Tatar by Valeyeva Alsu.

There's a Tatar villag Kirlie in the suburbsl of Kazan,
Even poultry in this village is a faithful music fan.

Not being born in that same village I felt happy at this place,
Plowed and sowed and cropped and harrowed, all the troubles did I face.

There, all around the village^ thick green trees are standing by
And a grassy velvet carpet lies beneath the azure sky.

Is the village big? You'll ask me. Well, I'll say, it's not so big.
Little spring of pure water gives a thirsty man a drink.

Neither hot nor cold is there, all is moderately wise:
Just in time the wind starts blowing and in time the sun will rise.

There you'll see a lot of berriues - hurry up to fill your pail!
You will gather in a minute pretty lot without fail.

Like the rows of mighty soldiers pins-trees, fir-tress standing by,
What a pleasure was to lay there staring at the sunny height.



Рәссам Фәрит Муллахмәт




Кадерле балалар, кайсыгыз рәсем ясарга яратмый, шул кул күтәрсен әле. Юкмы андыйлар? Юктыр шул, чөнки РӘСЕМ ясарга яратмаган бала булмый.

Рәсемне бик оста ясаучыларны РӘССАМ диләр. Оста рәссамнарның иҗатын СЫНЛЫ СӘНГАТЬ дип йөртәләр. Җыр сәнгате, театр сәнгате, кино сәнгате бар. Сынлы сәнгать – шуларның иң өлкәне. Безнең борынгы бабайлар, әле тау куышларында яшәгәндә үк, торакларының диварларын рәсемнәр белән бизәгәннәр.



И. Левитан. **«Ташу».**



«Архангельское» бакчасы.



З. Серебрякова. **«Курчак тоткан кыз».**

Рәсем дәресе

Рәссам дөньяны чынбарлыктагыча, ләкин шул ук вакытта бары тик үзе генә күрә белгәнчә сурәтли.

Сынлы сәнгать – үзе бер дөнья. Аның үз теле бар. Ул телдә «нәкышь», «графика», «скульптура» дип сөйләшәләр. Нәкышьчеләр пумала һәм буяулар белән, графиклар күмер һәм карандаш белән, скульпторлар балчык, таш, пластилин, агач, металл, гипс белән эшлиләр.



«Акварель», «гуашь», «темпера», «пастель» дигән матур сүзләре бар бу телнең. Тагын «портрет», «пейзаж», «натюрморт» дигәннәре, «палитра», «композиция» дигәннәре дә бар. Без аларның нәрсә аңлатканын соңрак белербез әле.

Ә хәзер, әйдәгез, зур игътибар белән сынлы сәнгать әсәрләрен карыйк.

Юлия Щетинкина,
рәссам.


НАТЮРМОРТ

И. Хруцкий. **«Чәчәкләр һәм җимешләр».**


МУЗЕЙ

Мәскәү. Кусково.

Картиналар һәм скульптуралар МУЗЕЙларда яки КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫнда, безнең өйләребездә яши.

Музейларда рәссам яки скульпторның үз куллары белән ясаган әсәрләре саклана. Ул картина яки скульптура ОРИГИНАЛ дип атала. Оригиналны бөтен кеше дә музейга барып карый алмый. Шуңа күрә типографияләрдә картиналарның күчермәләрен бастыралар. Алар РЕПРОДУКЦИЯ була. Бу биттәге картиналар да – репродукция.

Өр-яңа мәзәк

Эш беткәч... көләргә ярый



Ике черки филне очрата. Берсе филгә әйтә:

— Фил, әйдә сугышабыз!

— Икегез берүземә каршымы? Юк, мин риза түгел...



Берүзең баядан бирле шыркылдыйсың. Җүләр мәллә син?

— Үземә үзем мәзәкләр сөйләгән идем. Бер мәзәкне моңарчы үземнең дә ишеткәнем юк иде. Шуңа көләм...



Әни, әйт әле, безнең эткә ничә яшь?

— Җиде!

— Миннән дә кечкенә! Алайса, нишләп аның койрыгы бар?



Әти, мин төшемдә синең өч морожный алганыңны һәм миңа биргәнеңне күрдем.

— Бик әйбәт! Үзең генә ашап бетер инде...

Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Салават күпере

9(115) — 1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛУМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ
1990 елның март аеннан бирле чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълумат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкның 1нче битендә
Светлана ЯРКОВА рәсеме

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.


«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тесләргә бүленде.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт


Производствога бирелде 17.9.99 ел.
Басарга кул куелды 17.9.99 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Офсет ысулы белән басылды.
Тиражы 12739 данә. Заказ 3-456.
Бәясе килешү буенча.

POINT®

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953



— Әти, әни! Сезгә әйтәм:
Мин хәзер эшкә китәм.
Аш пешереп торыгыз,
Идән юсын берегез...
Тәртип булсын, белегез!



— Сезнең хәлләр әйбәттер шул...
Минем менә үз хәлем.
«Ничек төшим икән?» — диеп
Җылап утырган мәлем.




— Туйганчы бал ашыйм, диеп
Кергән идем кичкырын...
Аю кычкыра: «Карак!» — диеп,
Мин: «Аю!» — дип кычкырам.






— Матур җырлар җырлый беләм,
Телим икән — биим дә...
Этем әйтә: — Шәп биисең,
Өйрәт әле мине дә!..



— Вилсәпидемә утырып,
Җыр җырлап барам сыман:
«Керим әле урманнарга,
Каеннар арасына...»



— Боргаланма, башкаеңны
Уңга-сулга каерма.
Маймылланмый гына утыр! —
Дидем маймылкаема.